Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№1 (52)

17 гыйнвар 2013 ел

## • Универ хәлләре

**9-11 ГЫЙНВАР КӨННӘРЕНДӘ КФУ**ның **АЛАБУГА ФИЛИАЛЫНДА ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕНЕҢ СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАРЫ ҖЫЕЛДЫ.** Тугыз кыз белән бер малай рус теле һәм әдәбияты буенча күп кенә конкурсларның җиңүчеләре булган. Университетыбызның Алабуга филиалында эшләүче тәҗрибәле белгечләре белән бергә алар үзләренең белемнәрен арттырды, шул рәвешле мәктәп укучылары республика олимпиадаларына әзерләнде. Остазлары белән берлектә тел тарихы, иске славян теле, лексика һәм фонетика кебек кызыклы темаларга дәресләр тыңлады. Әле ул гына да түгел, Түбән Камадан килгән яшь кунакларга Алабуганың музейларына сәяхәт тә оештырылды.

• • • •

Шушы көннәрдә **МӘГЪЛҮМАТИ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ҺӘМ СИСТЕМАЛАР ЮГАРЫ МӘКТӘБЕНДӘ UNITY** (Мультиплатформалы иснтрумент), **CISCO** (элемтә җиһазлары) һәм **FUJITSU** (серверларны администрацияләү) буенча **КУРСЛАР ТӘМАМЛАНДЫ**. Тантаналы рәвештә курсларга йөрүчеләргә сертификатлар тапшырылды.

Бу исә КФУның Мәгълүмати Технологияләр һәм системалар югары мәктәбенең шушы курсларын тәмамлаучы укучылар өчен уңышка ирешергә мөмкинлекләр тагын да арта дигән сүз. Чөнки бу мәсләкне үзләштерүчеләр бүгенге көндә иң кирәкле хезмәткәрләр булып санала. IT-профессияне үзләштерергә теләүчеләр турыдан-туры югары мәктәпкә мөрәҗәгать итә ала.

• • • •

Яңа елның 4-8 гыйнварында, кышкы каникул көннәрендә, «Планета Эрудитлары – 2013» **ХАЛЫКАРА ОДИМПИАДАСЫ УЗДЫРЫЛДЫ**. Чара Мәскәүдә Россия һәм чит ил мәктәп укучылары һәм студентлары өчен үткәрелде. Олимпиада уздыруның төп максаты – балаларда иҗади үзенчәлекләрне арттыру, интеллектуаль потенциалларын һәм яңа талантлар ачу. КФУның IT Лицей командасы да бу ярышта актив катнашты. Нәтиҗәдә, алар үзләренең күзаллау киңлекләрен арттырды; булган белемнәрен, логик фикер йөртү сәләтләреннән файдаланырга өйрәнде; гадәттән тыш хәлләрне дөрес итеп чишү юлын эзләде; чикләнгән вакыт эчендә бер команда булып эшләү күнекмәләрен булдырды. Җиңүчеләргә дипломнар, медальләр, кубоклар һәм истәлекле бүләкләр бирелде. IT Лицей командасына да «Югары нәтиҗәләргә ирешкән өчен» кубок, медаль, сертификатлар һәм дипломнар тапшырылды.

• • • •

**КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ГУМАНИТАР ГАЛИМНӘРЕ ИҖАДИ КОЛЛЕКТИВЫ** (Р.Г.Минзарипов – җитәкчесе, Л.М.Попов, А.О.Прохоров, М.Д.Щелкунов) 2012 ел нәтиҗәләре буенча, **МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНДӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ХӨКҮМӘТЕ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕНӘ КЕРТЕЛГӘН**. Лауреатларны тәбрикләү тантанасы Яңа ел аралыгында Мәскәүдә Россия Федерациясе Хөкүмәт йортында узды. Анда РФ Хөкүмәте башлыгы Дмитрий Медведев һәм РФ Мәгариф һәм фән министры Дмитрий Ливанов та катнашты.

• • • •

**КФУ** «Каспиан Энерджи Ресерч» җаваплылыгы чикләнгән ширкәте белән берлектә Казахстанда «Caspian Integrated Technologies» дип исемләнгән уртак проектлы-инжиниринглы **ПРОЕКТ БУЛДЫРЫРГА ҖЫЕНА**. Әлеге предприятияне барлыкка китерү турында бер ел элек КФУ ректоры И.Гафуров «Каспиан Энерджи Ресерч»ның генераль директоры А.Джамикешов белән булган очрашудан соң сүз кузгаталар. Килешүгә 19 декабрь көнне Алма-Ата шәһәрендә кул куела. Документка КФУ ягыннан фәнни эшчәнлек буенча проректор Д.Нургалиев, Казахстан ягыннан «Каспиан Энерджи Ресерч» вәкиле Р.Бегаширев кул куя.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



# «КФУда мөмкинлекләр күп…»

**Динара МИННЕКАЕВА,**
хәбәрче

16 гыйнвар көнне В.Н.Каразин исемендәге Харьков милли университетыннан килгән делегация КФУ ректоры Илшат Гафуров һәм уку йорты җитәкчелеге белән очрашты.

Чарада КФУның уку-укыту эшләре буенча проректор Рияз Минзарипов, фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиев, административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе Андрей Хашов, инновацион эшчәнлек буенча проректор Наил Кашапов, тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов һәм кайбер институт директорлары, профессорлар катнашты.

Кунаклар: В.Н.Каразин ис. Харьков милли университеты ректоры Вил Бакиров, фәнни-педагогик эшләр буенча проректорлар Николай Азаренко һәм Зариф Назыйровны Илшат Гафуров Казан федераль университеты эшчәнлеге белән якыннан таныштыру өчен, презентация тәкъдим итте. Фундаменталь медицина һәм биология институты директоры Андрей Киясов та үзе җитәкли торган яшь бүлек белән таныштырды. Әйтергә кирәк, уку йорты эшчәнлеге, ирешелгән уңышлар, киләчәккә планнар Украина галимнәрендә зур кызыксыну уятты. Харьков университеты ректоры: «Бүген күргәннәремне, ишеткәннәремне сүзләр белән генә аңлатып булмый. Бик күптән Казан федераль университетын күрәсем килә иде. Дөресен әйтергә кирәк, бездә мондый мөмкинлекләр, грантлар юк. Абитуриентларны җәлеп итү дә авыр, чөнки яшьләрне хәзер хокук, икътисад кызыксындыра. Күп очракта алар укымыйча гына диплом алырга телиләр», – диде фикерләре белән уртаклашып.

Кунаклар үз уку йортлары турында да мәгълүмат җиткерде. Зур тарихы булган Харьков милли университеты үзенең беренче ректоры В.Н.Каразин исемен йөртә. Егерме факультет һәм алты институтны берләштергән вузда уналты мең биш йөз студент утыз сигез юнәлеш һәм алтмыш ике белгечлек буенча белем ала. Кече Каразин интситутына да инде ун ел булган. Биредә мәктәпкәчә кадәр яшьтәге балаларны да алалар. Алар ун ел укый. Кече институт шуның белән үзенчәлекле: нәни укучылар үз фәнни хезмәтләрен яза һәм бастырып чыгара.

Казан федераль университеты һәм В.Н.Каразин ис. Харьков милли университеты 2012 елның июль аенда үзара хезмәттәшлек итә башлады. Бу очрашуда исә ректор Вил Бакиров социаль-гуманитар фәннәр буенча да бергә эшләргә тәкъдим итте. «Бездә татарлар бик күп, сездә дә Украина студентлары укый. Алар белән төрле фәнни тикшеренү эшләре язарга, социаль мониторинглар үткәрергә мөмкин булыр иде», – диде һәм Украинага кунакка чакырды.

Очрашуның рәсми өлешеннән соң, кунаклар КФУның Тарих музее, Технологик үзәк, А.М.Бутлеров ис. химия институты, Физика институты белән танышты, инновацион проект авторлары белән аралашты.

Украина галимнәренең уку йортыбызга визиты бүген дә дәвам итә. Алар Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты, Экология һәм география институты, Фундаменталь медицина һәм биология институты белән таныша. Шулай А.Н.Штукенберг ис. Геологик Музеена һәм Казан Кремле буенча да экскурсия үтәчәк.

*Рәсемдә Вил Бакиров.*
Руслан Гиниятов фотосы

## • Ректорат

# Яңа елда беренче җыелыш

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

16 гыйнвар көнне 2013 елның беренче ректораты узды. Утырышны ректор Илшат Гафуров башлап җибәрде.

Иң беренче ул аспирантура тәмамлаучыларга филиаллар базасында университет стандартларына туры килә торган профессиональ яраклылыкка апробация үтәргә кирәк булачагын әйтте. «Әгәр без аспирантларга кирәкле шартлар тудыра алмасак яисә алар безнең университетта калырга теләмәсәләр, Алабуга һәм Чаллы филиалларында калу мөмкинлекләре булачак. Университет аларны торак белән тәэмин итәргә әзер», – диде ректор.

Алга таба Илшат Гафуров КФУ базасында IT өлкәсенә караган дөньякүләм дәрәҗәдәге тикшерү үзәкләрен үстерү буенча тәкъдим булганын әйтте.

**Ахыры 2нче биттә.**



Әмир Фазлыәхмәтов фотосы

# Яңа елда беренче җыелыш

**Башы 1нче биттә.**

«Бу конкурс, ким дигәндә, 5 елга каралган һәм тулы финанслау булачак», – дип билгеләп үтте ул. Чыгышының соңгы өлешендә ректор институт директорларына үзләренең хезмәт коллективлары белән узган ел нәтиҗәләре буенча очрашу уздырырга өндәде. Шулай ук кафедра җитәкчеләре белән бәйләнешкә кереп, аларның тикшерену эшләренең өстенлекле якларын төгәл билгеләп куярга кирәк булачак. Мегагрантларга әзерлек турында да онытмаска кирәк,- диде Илшат Гафуров.

Контроль йөкләмәләр үтәлешенең торышы белән административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе Андрей Хашов таныштырды. Аның сүзләренчә, бүгенге көндә планлаштырылган эшнең үтәлмәгән бер генә пункты да юк. Университетның база мәктәпләренә видеомониторлар урнаштыруга тулысы белән диярлек әзер. Ул 7нче гимназия, Лобачевский исемендәге гимназия, татар гимназиясе, IT лицей һәм элеккеге 131 нче мәктәп (анда әлегә ремонт эшләре алып барыла). Проректор сүзләреннән соң, Илшат Гафуров китапханә директорына филиалларга чыгып, безнең китапханә мөмкинлекләре белән, шул исәптән китап фонды белән дә таныштырырга һәм аларны күрсәтергә кирәк булыр, дип әйтте.

Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институты директоры Владимир Чугунов үзе җитәкли торган институт үсешенә керткән үзгәрешләре турында сөйләде. Әлеге институт математика фәне буенча РФ югары уку йортлары арасында 16 урынны алып тора. Математика буенча уртача БДИ баллы – 65. Бу югары күрсәткеч түгел. Университет эчендә 19 институт арасында Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институты 13 урында тора. Соңгы елда институт барлыгы 7 550 000лек 13 грант откан. Уку-укыту эшләре буенча проректор Рияз Минзарипов: «Булачак студентларны җәлеп итү өчен, кызыграк чаралар уйлап табарга кирәк. Укытучылар һәм мәктәп директорлары белән генә эшләү бүгенге көндә җитәрлек түгел», – диде.

Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин булачак тикшеренүләр уңаеннан, барлык объектларны инвертаризацияләргә өндәде.

Социаль һәм тәрбия эшчәнлеге буенча проректор Ариф Межведилов 2013 елгы Универсиадага әзерлек эшләрендә катнашкан волонтерлар һәм җаваплы кураторларның теркәлү нәтиҗәләре белән таныштырды. «Тулаем алганда, эшләр зарланырлык түгел. Кайбер институтларның хәл итә алырлык вак проблемалары бар, ә менә Тарих инситуты һәм Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтында хәлләр мөшкелрәк», – дип билгеләде проректор.

Андрей Крылов КФУ сайтының инлиз телендәге торышы белән таныштырды. Инглиз телен белүче һәр чит ил студенты да КФУ сайтына кереп андагы мәгълүматны укый ала. Алар бары тик уку планы программалары белән генә таныша алмый. Һәр институт турында да мәгълүмат чагылырга тиеш дигән фикер яңгырады.

Инна Лукашина КФУның оештыру-регламент документлары турында сөйләде. 2012 елның 29 декабренә төп эшчәнлек буенча приказлар – 1200, регламент нигезләмәләренең саны 201 булган. Шулай ук, И.Лукашина сайтта әлеге документларның үрнәге булуын да әйтте.

● Хәзинә

# «Җуелмас байлык» нинди ул?

**Динара МИННЕКАЕВА,**
хәбәрче

14 гыйнвар көнне Казан федераль университетының Актлар залында «Җуелмас байлыклар» («Непреходящие ценности») альбом-китабын тәкъдим итү кичәсе узды. Чара альбомның төп инициаторы Василий Савельев истәлегенә багышланды.





Диана Поварова фотолары

Бер яктан уку йортыбыз өчен, китап авторлары өчен бу көн шатлыклы булса, икенче яктан, бер күңелсез хәлне дә искә төшерергә дә мәҗбүр итте. Нәкъ ике ел элек Казан университетының бөтен матурлыгын, эчке һәм тышкы байлыгын, ике йөз елдан артык тарихын җыеп укучыларына җиткерү хыялы белән янып йөргән кеше арабыздан бакый дөньяга күчә. Василий Петр улы Савельев үзенең актив, лидер, галим, яхшы оештыручы буларак хезмәттәшләренең күңелен яулый. Казан университеты – аның икенче йорты була. Биредә ул үзенә яшәр өчен дәрт, көч-куәт ала.

1962 елда В.Савельев КДУның химия факультетына укырга керә һәм биредә мәңгелеккә кала. Диссертация яклый, укыта, 1980-87 елларда фәнни эшчәнлек буенча проректор урынбасары вазифасын башкара, УНИКС концертлар залының беренче директоры була. Шаян күңелле Василий әфәнде 8 ел дәвамында «Студентлар язы» фестиваленең һәм «КВН»ның жюри рәисе буларак та мәңге истә калыр. Аның актив эшчәнлеге белән профессорлар В.Г.Семенов, М.В.Николаев, С.В.Мокичев ярдәмендә икътисад факультеты ачыла. Шулай ук Василий Савельев тырышлыгы белән Татарстанда күп кенә дәүләтнеке булмаган беренче югары уку йортлары барлыкка килә. Аның соңгы уңышлы проектларының берсе булып «Казанский социально-гуманитарный вестник» журналы тора. Басма бик күп иҗат һәм фән кешеләрен үз канаты астына ала.

Василий Савельев, чын мәгънәсендә, иҗат кешесе булган. Казан университетының корпоратив билгесен ничек ясарга дип уйлап йөргәндә, төп бина капкасындагы сурәт аңа юнәлеш бирә. Нәтиҗәдә бик матур билге килеп чыга.

Василий әфәнденең зур хыялы тормышка ашмый кала. Ул «Минем университет» дигән китап язарга: анда эшчәнлеге, аралашкан кешеләре, ирешкән уңышлары турында бәян итәргә тели. Хәтта китапның исемен дә уйлап куя. Нишлисең, язмыштан узып булмый... Тик шулай да дуслары, дәвамчылары һәм укучылары ярдәме белән «Җуелмас байлыклар» альбомы дөнья күрә. Ул 500 данә тираж белән Казан нәшрият йортында басыла. Авторлар арасында Юрий Королев, Валентин Королев, Тимур Шәйхетдинов та бар. Тормышта бер нәрсә дә очраклы түгел. Альбомның Василий Савельевка 70 яшь тулган елда дөнья күрүе, аның ни дәрәҗәдә хыялланып яшәве турында сөйли.

Биредә уку йортының бөтен гүзәллеге, һәр сулышы, үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге урын алган. Нәкъ шулай! Автор якты фотосурәтләр аша киләчәккә өмет, ышаныч уята. Һәр кадр самими мәхәббәт һәм чын горурлык хисләре белән сугарылган. Альбомны караганда, фотоларның матурлыгына карап кына сокланмыйсың, ә Казан университеты турында да шактый мәгълүмат аласың. «Гомер бик тиз уза. Без барыбыз да каядыр ашыгабыз. Бәлки уңышның нигезен дә шул ашыгу тәшкил итәдер... Ә менә бер мизгелгә генә туктап, тирә-якны күзәтеп, аның гүзәллеген күрә белсәк иде. Минемчә, Василий Петрович нәкъ шушы фикерләрне әйтергә теләгән», – диде тормыш иптәше Татьяна Савельева.

Күктә кайбер йолдызлар бик якты яна, кайберләре күзгә дә күренмәскә мөмкин. Күп яхшылыклар эшләгән, үзенең изге гамәлләре, үҗәтлеге, тырышлыгы белән башкалар күңелен яулаган Кешеләр дә иң якты йолдызга әверелә. Җирдәге якты йолдызга! Василий әфәнде дә бик күп кешеләр күңелендә үзенең шундый якты шәхес булуы белән истә калыр.

● Яңа китап

# Румыниядә татар халкы тарихын өйрәнәләр!

**Альберт БОРҺАНОВ,**
Тарих институты профессоры



Декабрь ахырларында Татарстан Республикасының Милли китапханәсенә «Mostenirea istorica a Tatarilor» (Bucuresti, Editura Academieli Romane, 2012, 804 бит) фундаменталь фәнни хезмәтенең II томы кайтты. Китап Бухарестта профессор Тасин Җәмил һәм доктор Нәҗи Пинару редакциясендә «Татарларның тарихи мирасы: Тарих, мәдәният һәм цивилизация» сериясендә румын, инглиз һәм төрек телләрендә чыккан.

Евразиядә яшәүче төрки халыклар һәм татарларның тарихына багышланган Халыкара фәнни симпозиумнарның Румыниядә үткәрү инициативасын югарыда әйтелгән сериядә хезмәтләр бастыруга зур өлеш керткән румын һәм татар галим-тарихчысы, профессор Тасин Җәмил күтәреп чыга һәм әлеге чараларны оештыра да.

Тасин Җәмил Бөтендөнья Татар конгрессы һәм Татарстан Фәннәр Академиясе уздырган татар галимнәре съездына Казанга килгән вакытында җирле галимнәр һәм Фәннәр Академиясе белән кирәкле фәнни элемтәләр булдыра. Күптән түгел генә румын профессоры декабрь аенда башкалабызда узган V Бөтендөнья Татар конгрессына үзенең якташларын да алып килгән иде.

Румыниядә чыккан татарлар тарихына багышланган хезмәт 2010 елның 6-10 октябрьдә Констанд шәһәрендә узган «Татарларның тарихи мирасы» II Халыкара фәнни симпозиум материаллары һәм докладлары нигезендә төзелде. Төп чыгыш ясаучыларның мәкаләләре «Mostenirea istorica a Tatarilor» II томының төп материалларына әверелде. Әлеге чарада Россия Федерациясеннән Казан федераль университетының Тарих институты профессоры А.Борһанов һәм Уфадан В.Әхмәтовлар катнашты.




■ *Конференциядә катнашучылар Румыниядәге татар җәмәгатьчелеге белән.* Автор фотосы

Китап Румыния Фәннәр Академиясе вице-президенты Дан Бериндейның котлау сүзләре белән башланып китә. Әлеге хезмәтнең Евразия халыклары арасында иң борынгылардан саналган татарларга багышланганын һәм аларның бер өлеше булган Румын татарлары исеме белән йөртелгән румын җәмгыятенең аерылгысыз өлеше булуын да билгеләп үтте Дан Берийден. Алга таба китапта профессор Тасин Җәмил һәм Румыниянең Татар һәм Төрек-мөселманнары Демократик Союз президенты Варол Аметның кереш мәкаләләре урнаштырылган. Т.Җәмил Татарстан галимнәренең татарлар һәм Евразиянең башка төрки-мөселман халыклары тарихын өйрәнүгә керткән өлешләре турында әйтә һәм «Татарлар тарихы»ның III томын бик югары бәяли.

Структур яктан караганда китап 8 өлештән тора. Анда танылган румын һәм чит ил галимнәренең 48 мәкаләсе кертелгән.

Әлеге хезмәт, һичшиксез, тюркология, көнчыгышны һәм татар халыклары тарихын өйрәнү өчен бик мөһим фәнни чыганак.

● Галимнәребез

# Чын ориенталист, ягъни Хөсәен Фәезханов турында

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

Ә СЕЗ ФӘН, МИЛЛИ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ӨЧЕН, ХЕЗМӘТ ХАКЫ АЛМЫЙЧА, ЭНТУЗИАЗМ БЕЛӘН ГЕНӘ ЭШЛИ АЛЫР ИДЕГЕЗМЕ? КУЛЫБЫЗДАГЫ БҮГЕНГЕ ФӘННИ МИРАСНЫ БУЛДЫРУ ӨЧЕН, КАТЛАУЛЫ ШАРТЛАРДА ЭШЛӘГӘН ШӘХЕСЛӘР ШАКТЫЙ. УНИВЕРСИТЕТ ТАРИХЫНДА МИЛЛИ МӘГАРИФКӘ, ТАТАР ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮГӘ ЗУР ӨЛЕШ КЕРТКӘН ГАЛИМНӘРЕБЕЗ ДӘ БАР. ШУНДЫЙЛАРНЫҢ БЕРСЕ – ТАРИХЧЫ-ГАЛИМ, КӨНЧЫГЫШ ТЕЛЛӘРЕ БЕЛГЕЧЕ, КАЛЛИГРАФ ХӨСӘЕН ФӘЕЗХАНОВ. БЫЕЛ АНЫҢ ТУУЫНА 185 ЕЛ ТУЛА.

Хөсәен Фәезханов 1828 елда Сембер губернасы Сабачай (Сафаҗай) авылында дөньяга килә. Егерме ике яшендә ул Казанга килеп, Шиһабетдин Мәрҗанидән дәресләр ала башлый. Укуында зур уңышларга ирешә, шуңа күрә 1854 елда аны көнчыгыш телләрне укытырга Петербургка эшкә чакыралар.



Казан университетының Көнчыгыш бүлеге 1855 елда Петербургка күчерелгәннән соң, А.К.Казембек һәм И.Н.Березин тәкъдиме белән, Х.Фәезханов ул вакыттагы башкала университетына төрки-татар теле укытучысы итеп эшкә алына.

Петербург укыту округы попечителенең бу уңайдан мәгариф министрына тәкъдим язмасында болай диелә: «Бу чын ориенталистны... төрек телләре кафедрасына алу файдалы булыр иде». Ләкин рәсми карар тоткарланып тора. Фәнгә үз өлешен кертергә омтылып, Х.Фәезханов башта хезмәт хакы алмыйча эшләргә ризалык бирә, тик «үзенең университеттагы хезмәтен чын хезмәт итеп санауларын» шарт итеп куя.

Петербург университеты җитәкчелеге һәм укыту округы попечителе министрлыкка яңа тәкъдимнәр белән керә. Мәгариф министры 1857 елның 24 ноябрендә генә Х.Фәезхановны Петербург университетының төрек-татар телләре укытучысы итеп билгеләргә рәсми рөхсәт бирә. Биш елдан соң, 1862 елда ул, Сенат указы белән, Көнчыгыш телләре факультетының лекторы итеп билгеләнә.

Табигый сәләте, гарәп, татар телләрен һәм әдәбиятын төпле белүе, аның га киң карашлы булуы Х.Фәезхановны «үз белгечлеге буенча кем генә мөрәҗәгать итсә дә, аларның барысына да файда китерергә әзер торучы иң укымышлы укытучылардан берсе» итеп таныта. Петербург университетында әллә ни озак эшләмәсә дә, Х.Фәезханов лектор-педагог буларак та, кеше буларак та үзе турында бик җылы тәэсир калдыра.

1858 елда Мәскәүгә тышкы эшләр архивына эшкә җибәрелә. Ул анда Кырым татарларына караган күп кенә материаллар алып кайта. 1864 елда Е.Зерновның «Материалы по истории крымского ханства» дигән фәнни хезмәте дөнья күрә. 1860 елда Хөсәен Фәезханов Касыйм шәһәренә археологик экспедициягә бара һәм 29 мөселман кабер ташларының күчерелмәсен алып кайта. Тарихчы Зерновтан материалларны файдалану өчен рөхсәт сорый, Касыйм ханлыгы турында яза. Мөселман кулъязмаларын тәртипкә китерү буенча да күп көч куя. Татар теле грамматикасы буенча дәреслек, төрки телләр сүзлеге һәм хрестоматияләр төзи. Бу – аның эшчәнлегенең ике әһәмиятле тармагы. 1862 елда «Краткая татарская грамматика» хезмәтен яза. Бүген Петербургта Хөсәен Фәезхановның 95 битлек китабының бер нөсхәсе саклана. Ул аны Мәхмүтов дәреслегенә нигезләнеп, җиде килеш, өч заманны билгеләп яза. 1861-1862 елларда Хөсәен Фәезханов «Чулпан» газетасы чыгару уе белән янып йөри. 1866 елда сәламәтлеге какшау сәбәпле, туган ягы Сабачайга кайтып, шунда вафат була.

Мәгърифәтче Хөсәен Фәезханов хөрмәтенә ул туып үскән Түбән Новгород өлкәсендә (1922 елда Сафаҗай авылы шушы өлкәгә күчерелә), 2005 елдан башлап, татар халкының этник, милли, дини тормышын, үткәнен яктыртуны максат итеп куйган «Х.Фәезханов укулары» исемле фәнни-гамәли конференция үткәрелә. Бирөдә Мәскәү, Түбән Новгород, Казан һәм кайбер башка шәһәр галимнәре Россиядә ислам мәгърифәтенең тарихы, бүгенге хәле, дини һәм дөньяви мәгариф учреждениеләренең үзара бәйләнеше, милли һәм башка актуаль мәсьәләләр турында фикер алыша.

Хөсәен Фәезханов – идея өчен эшләүче, фәннең алга китешен максат итеп куйган татар мәгърифәтчеләренең күренекле вәкиле.

*Мәгълүмат Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты чыгарган Яхъя Абдуллинның «Татар әдәбияты тарихы» китабының икенче томыннан алынды.*

● Тарих сәхифәләреннән




*1913.*
☛**11 гыйнварда** Россия Министрлар советы Император фәннәр академиясенә Россиянең Магнитлы төшерү эшләре өчен ведомствоара коллегия төзү мөрәҗәгате белән чыга. Фәннәр академиясе үз чиратында Казан Император университетының бу комиссияне төзүдә катнашуын сорый.

*1923.*
☛**16 гыйнвар көнне** РСФСР Совнаркомы карары нигезендә кайбер вузларга, шул исәптән Казан Дәүләт университетына «Чит ил югары уку йортлары һәм белем бирү учреждениеләре белән фәнни тәҗрибә алмашу» хокукы бирелә.

*1933.*
☛**15 гыйнвар көнне** КДУда Ленинизм һәм ВКП(б) тарихын өйрәнү кафедрасы, 16 гыйнварда агрономик химия кафедрасы ачылды.

*1943.*
☛**1 гыйнвар көнне** РСФСР Мәгариф наркомы фәрманы белән КДУга керү буенча сигез айлык әзерлек курслары эшли башлады.

*1953.*
☛**14 гыйнвар көнне** Г.Тукай исемендәге стипендиягә Тарих-филология факультетының дүртенче курс студентлары Ф.Ганиев һәм Н.Юзеев; Н.Г.Чеботарев исемендәге стипендиягә физика-математика факультеты студентлары А.В.Галашин (2 курс) һәм В.Д.Третьяков (5 курс); ВЛКСМның XV еллыгы исемендәге стипендиягә Тарих-филология факультеты студенты Н.М.Лазько лаек булганлыгы игълан ителде.

*1963.*
☛**17 гыйнвар көнне** Н.Г.Чеботарев исемендәге Математика һәм механика буенча фәнни-тикшеренү институтының санау теорияләре бүлегендә кибернетика буенча махсус төркем булдырыла. Төркемнең җитәкчесе итеп доцент Р.Бохараев билгеләнә.

● Кышкы ял

# Каникуллар тукталышы


**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты студенты

Эх, сессия, сессия!.. Әле беренчесе генә булгангамы, сине түземсезлек белән көтеп алдык. Күпме көч һәм тырышлык куйдык без сине татып карар өчен. Рәхәт тә икән шул сессия дигәннәре!.. Уку юк, көне-төне йокла да, йокла инде. Алай гына булса иде ул! Имтиханнар бирәсе бар бит. Шуңа күрә бөтен башны, акылны шул эшкә җиктек. Аллага шөкер, беренче «Сессия» тукталышын хәвеф-хәтәрсез уздык. Сессия тукталышыннан соң безне күптән көтелгән, ике атналык мавыктыргыч ял көтә иде. Нинди инде ул? Бик дөрес «Кышкы каникуллар»! Рәхим ит дустым, әлеге тукталыш бүген синеке!


Ике атна вакыт! Бер карасаң, студент өчен ничек озын! Үз-үзеңә нинди генә планнар куеп бетермисең: монысын эшлим, тегесен эшлим, анда барам, монда барам... Ниятләрең тормышка ашса, бер дә эшсез калырмын дип борчылып атасы юк – авылда эш җитәрлек! Каникулның беренче көннәре Яңа елны каршы алу белән узып та китте! Һәммәбезгә дә таныш шундый әйтем бар: «Яңа елны ничек каршы алсаң, елны шулай уздырасың». Алла боерса, бу елны да күңелле, шатлыклы, уңышлы гына уздырырмын дим, чөнки Яңа елны иң якын кешеләрем – гаиләм белән каршы алдым. Көннәрне чаңгы, тимераяктa шуып та уздырдым. Телевизорны бик сагынган идем, кичләрем кызык кинолар карап үтте. Бер сүз белән әйткәндә, каникуллар күңелле дә, файдалы да узды. Ә КФУ студентлары каникулларын ничек уздырган икән? Әйдәгез, бергәләп танышыйк.



**Гөлинә Гайнуллина** (3 курс Математика һәм механика институты): «Каникул сизелми дә үтеп китте. Беркая да бармадым, авырдым. Шулай да клубта үткән чыршы бәйрәмен карап килдем. Каникулның соңгы көнендә яшьләр белән клубта уеннар үткәрдeләр, анда катнаштым. Аллага шөкер, бу Яңа ел яхшы гына башланып китте. Барчабызга да сәламәтлек телим! Бу ел яңа шатлыклар, яңа куанычлар алып килсен».



**Гөлчәчәк Хөснуллина** (3 курс Филология һәм сәнгать институты): «Кышкы каникул бик күңелле үтте, якын дуслар, туганнар белән күрешеп, аралашып кына калмыйча, үзем дә кунак булып йөрдем. Чыннап торып маҗаралы, могҗизалы Яңа ел булды. Мәктәптә, мәдәният йортында узган маскарад кичәләрен карап кына калмадым, үзем дә катнаштым, җырладым. Шуның өстенә бүләкләр алу тагын да куанычлы булды. Өч атнага якын сузылган каникул вакытында өйдә ятып төркемдәшләремне сагындым, алар белән аралашып, хәлләрен белешеп тордым. Хәзер яңа көч туплап, укырга килдек. Бу уку елы да шундый ук нәтиҗәле, күңелле булыр дип ышанып калам!!!»




**Алсу Шәйхетдинова** (1 курс Математика һәм механика институты): «Өйдә ятарга буш вакытым бер дә булмады. Чыршы бәйрәмнәренә йөрдем, концертлар карадым. Рәхәтләнеп биедек, җырладык. Бу кышкы каникуллар бик күңелле үтте».



**Альбина Вәлиева** (1 курс Филология һәм сәнгать институты): «Мин каникулларда Башкортстанга кайттым. Ялны күбесенчә әти-әнием белән үткәрдем. Дусларым белән боз сараена бардык, Нефтекамск урамнары буйлап йөрдек».





**Раил Садретдинов** (1 курс Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр факультеты): «Минемчә, бүгенге көндә ялларын шәп һәм файдалы итеп үткәрәм дигән кешегә барлык мөмкинлекләр дә бар. Тели икән, чаңгыда шуа ала, теләсә, боздa шуарга бара, көне буе интернетта, телевизор алдында утырырга гына димәгән бит! Каникулларда һава торышы бик яхшы булды. Үземә килгәндә, кышкы ялларны авыл баласы булгач, әлбәттә инде, авылда үткәрергә туры килде. Рәхәтләнеп чаңгыда шудым, тимераяктa йөрдем, бик теләп әти-әниемә ярдәм иттем, озак күрешми торган дусларымны очраттым. Тик яллары гына тиз үтте. Ник шулай икән ул?!»

Чыннан да, ник шулай икән ул? Бу җавапка тиз генә җавап биреп булмый, мөгаен. Ләкин шунсына ышанасы килә: «Яңа сессия» тукталышын да тиз арада җиңел, уңышлы гына үтеп китсәк иде!

• Әкәмәт

# Ирекле песи

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

Иртәләрен ул сиңа назлы гына кагылып уята, күзләреңә туры карый, синең белән бергә аш бүлмәсенә атлый, иркәләнә. Ихлас яратумы? Юк, ашыйсы килә аның! Песи. Әгәр дә синең йортыңда мәче бар икән, димәк, ул – синең тормышыңның аерылгысыз бер өлеше.



Атна-ун көнгә берәр кая китәргә җыенсаң, өйдә песи барлыгы синең ниятләреңне чәлпәрәмә китерергә мөмкин. Кайбер «акыллылар» күп итеп ризык әзерләп, песине озакка өйдә калдырып, тынычлап ял итәргә китә. Хуҗа кайтуына песинең ертык обойлар, умырылган диван һәм тагын төрле кызык нәрсәләрдән «сюрприз» әзерләве бар. Җитмәсә, өеңдә калган дүрт аяклы дустың фатирыңны үзенчәлекле «хуш искә» дә күмәргә мөмкин.

Шулхәтле күп мәшәкать китереп чыгаргач, безнең өйдә кайдан килеп чыктың соң син, Кузя? Әйе, ул вакытта син кечкенә, йомшак, самими карашлы ап-ак песи баласы идең. Һәрвакыт шулай сөт кенә эчеп, назлы итеп мырлап, диванда түгәрәкләнеп ятып, шатлык вә куаныч китереп, матур һәм тәрбияле булып кына йөрерсең кебек иде. Ләкин заманалар үзгәрә, президентлар алышына, технологияләр үсеш кичерә, шул исәптән Кузя да. Аңа хәзер Кузя дип ягымлы эндәшү дә ничектер килешми кебек тоела башлады.

Ул вакытта әле мәктәптә генә укый идем. Укудан кайтып керүгә, ишек янында мине каршы аласың. «Сине көне буе шушында көтеп утырдым», – димәкчеме? Шыттырма, Кузя, ачылыр-ачылмас күзләрең, бегемот кадәр итеп авыз ачуыңнан көне буе нишләгәнеңне аңлау кыен түгел.

Мин чәй эчәм – син «китекат» кетердәтәсең. Мин савыт-сабалар юам – син черем итеп аласың. Мин ашарга пешерәм – син креслога ябышып, тырнакларыңны кайрыйсың. Шәһәр фатирында яшәү рәхәт булгандыр сиңа, ә!

Тик язмышың сине авыл белән бәйләде дә куйды. Шулай итеп, әдәбият укытучысы сөйләгәндәй, Кузяның тормыш юлын ике этапка бүлеп карарга була. Үзең гаепле! Булганына канәгать калып, тыныч кына утырасы иде. Ә син әче таңнан ишек янына килеп, кычкырып мияуларга тотындың. Башта мин сине әллә берәр үзенчәлекле мәчеләр догасы әйтәме, дип уйлый идем. Ә сиңа нибары ирек кенә кирәк булган икән. Хе-хе, «Азатлык» кычкырып кына, бәйсезлек алып булмый шул ул, мәче дус!

Сиңа бераз ирек бүләк итеп, фатир ишек төбендәге гомуми коридорга чыгара башладык. – Бәлки, сиңа коридорның «саф һавасы» булса да ярап торыр? Әмма син мондый шартларга да канәгать булмадың – көннәрдән бер көнне юкка чыктың. Сине эзләп җаннар чыкты! Урамнан, йортның башка катларыннан эзләдек, чакырдык. Күршедә яшәүче абыйның ишегән шакып: «Минем песине коридор ишегеннән син чыгарып җибәрдеңме, оятсыз!» – дип ачуланырга да теләгән идем, әни рөхсәт итмәде. Шулай да син табылдың. Беркөн әни белән подъездан чыгып барганда, ватык лифт яныннан песи тавышы ишетелде. «Кузя, Кузя!» – дип чакырды әни, лифтның ачылыр-ачылмас ватык ишеге янына килеп. Бер мизгелдән лифттан син атылып чыктың: карага буялган, ябыккан, мескен хәлдәге Кузя. Ашыгуыбызга карамастан, без сине тизрәк өйгә алып кердек, юындырдык, йоныңны тарадык. Протест игълан итү менә нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин, песием! Әле ярый беренче катта торабыз, лифт шахтасы бездән бер метр гына түбән. Өстәге катта яшәсәк, сине бер Бразилия сериалындагы Клебер исемле адәм язмышы көтә иде – шахтага төшеп харап буласы идең бит.

Син кабат «өй тоткынына» әверелдең – коридорга да чыгармый башладык. Иртәнге дүрттә ишек янында ялваруларың көчәйде, татлы йокысын калдырып, сине башмак белән тукмарлау әнине дә туйдырды. Без сине авылга, Резидә апаларга кайтарып куярга булдык. Гадәттә, шәһәр кешеләре киелми торган киемнәрне, кирәкмәгән йорт җиһазларын «авылда кирәге чыгар әле», дип кайтара. Ә без кирәкмәгән песине авылга илттек. Бу урында мөхтәрәм укучыларның күз яше сыгылып чыгарга тиештер.

Бер-ике атнадан без янә авылга кайттык. Әлбәттә, мин сине күрергә ашыгып, Резидә апаларга юл тоттым. Ике атна эчендә син инде үзеңне биредә шәп ерткыч буларак танытырга өлгергәнсең: апаның егерме (!) чебиен тотып ашагансың.

Балда-майда гына йөзгән, ап-ак тиреле, зифа гәүдәле, китекат белән вискас кына ашап үскән Кузябызны кырыс авыл, ишегалды шартлары ике атна эчендә шәп кенә үзгәрткән. Нәзакәтле вә пөхтә Кузя урынына минем каршыма симез, йоннары корымга буялган, бер җирендә тиресе купкан, оятсызлыгы йөзенә чыккан авыл песие килеп басты. Абау, Кузя, сикәлтәле тормыш юллары нишләткән сине?!

Шулай да иң сәер күренеш әле алда булган икән. Рәхәтләнеп чәй эчеп утырганда, синең җинаятьчеләрнекенә охшап киткән йөзең кухняда пәйда булды. Син ашарга сорадың, моңа беркем игътибар итмәде. Берничә секунд эчендә син чүп чиләге өстенә сикереп менеп, аны аудардың да мыш-мыш килеп иснәнергә тотындың. Шул ук мизгелдә Резидә апаның көчле аягы сине зал ягына «очырып» җибәрде.

Бер-ике елдан, инде авыл тормышына ияләшеп, мәче туйлары уздырып, рәхәт чиккәч, якты дөнья белән дә хушлаштың. Бирегә син кайтканчы, авылда ак песиләрне очратканым юк иде. Ә хәзер андыйлар еш күренә, очраткан саен үземнең ак песине искә алам. Күңелемдә ак барс кебек йомшак, ирекле тормышка ирешкән, азатлык образы син, Кузя!

• Шигъри башваткыч

## *Баобабай - 2*

**Ринат НУРУЛЛИН**

*Баобабта Көне Буе*
*Кайнашты Бабай Кичә,*
*Бүген Кабат Баобабның*
*Корган Ботагын Кисә.*

*Батты Кояш, Бытбылдыйлар*
*Кения Былбыллары.*
*Канәгать Бабай, Кымшата*
*Балалайка Кылларын.*

*Баяныңны Куй Ботакка,*
*Картлач Белән Кабызсак –*
*Бии Кемдер, Бабай Көйли:*
*«БАОБАБ = КОРГАН + БОТАК».*

*Күрерсең Бу Кәлимәдә*
*Башваткычлар Кенәзен –*
*Беразга Кушсаң Беразны,*
*Кашырсың Баш Көнозын.*

*«БАОБАБ» Күпме Булуын*
*Кемнәр Белер? Кыскасы,*
*Беренчегә Картлач Бирер*
*Карабодай Боткасы.*

*Килгәнсең Баскыч Күтәреп,*
*Баскычың Кирәк Булмас.*
*Күңел Бирсәң, Кирәк Бары*
*Кәгазь Белән Карандаш.*

*(Башваткычның дүрт чишелеше бар.)*

*Узган 20 декабрь санында чыккан башваткычның җаваплары:*

*450196 + 45298 = 495494;*
*450198 + 45296 = 495494;*
*450296 + 45198 = 495494;*
*450298 + 45196 = 495494;*
*540197 + 54398 = 594595;*
*540198 + 54397 = 594595;*
*540397 + 54198 = 594595;*
*540398 + 54197 = 594595.*

*! Бу турда җиңүче исеменә һәм «Альпинист үрмәкүчләр» китабына Дилүс ШӘРИФУЛЛИН лаек булды. Алинә Ганиева икенче, Алинә Галимова өченче урында. Алар барсы да башваткычның бөтен җавабын да белгән. Ә Нурсөя Минзина иң өлгере булса да, бер генә җавап язган. Шул сәбәпле дүртенче урынга лаек булды.*

*ШБ лигасы турында мәгълүматны vk.com/darelfonyn адресы буенча белергә мөмкин. Киләсе саннарның берсендә лигага нәтиҗә ясыйбыз.*

*КОРГАН + БОТАК= БАОБАБ тигезләмәсен чишеп, җавапларын электрон почтабызга языгыз! Җиңүчеләрне бүләкләр көтә!*

• Сәламәтлек

# Дөрес туклану - сәламәтлекнең нигезе

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче



Ни кызганыч, «Студентлар ашказаны һәрдаим ачлык белән көрәшә» дигән гыйбарә күп очракта дөреслеккә туры килә. Аларның ашавы, бигрәк тә тулай торактагыларныкы, еш кына «аягүрә туклануга» кайтып кала. Чипсы, чикләвек, «Кириешки» сохариларын ашап ашказаны үз эшчәнлеген дөрес башкара алмый башлый, бетә. Шуңа күрә ашказаны авырулары, гастрит, ашказаны җәрәхәтенең күп очракта 18-24 яшьлек яшүсмерләргә туры килүе дә очраклы түгел.

Бердән, кичә генә әти-әни карамагыннан чыккан студентлар ничек туклануга, гомумән, игътибар итми. Күп очракта көннәр буе ашамыйча йөрергә, йә булмаса шул ач карынны тон җиткәч, йоклар алдыннан бер көнлек итеп тутырып куярга мөмкиннәр. Икенчедән, әледән-әле фастфудлар белән тукланган организм ничек чыдасын ди инде?!

Бөтендөнья сәламәтлекне саклау оешмасыннан алынган мәгълүматларга караганда, кешенең гомер озынлыгы һәм саулыгының 60%ы аның дөрес туклануыннан, 15%ы – нәселдән, тагын 15%ы – әйләнә-тирә мохиттән һәм тагын 10%ы – медицина ярдәме күрсәтүчеләрдән тора икән. Гаҗәп түгел: дөрес туклану – сәламәтлекнең нигезе. Пәйгамбәребез (с.г.в): «Адәм баласының дөньяда торуына ризыкның беразы да җитә, шуның белән үз-үзеңне тәэмин итәргә мөмкин. Ашаганда карынны өчкә бүләргә кирәк: бер өлеше – аш, икенче өлеше – су, өченче өлеше – һава өчен калырга тиеш». Чыннан да, нинди дөрес сүзләр! Бүгенге көндә күп һәм режимсыз ашау – күп авыруларның чыганагы. Табиблар да моны әледән-әле дәлилләп һәм искәртеп тора.

Азыкның составы, үзенчәлеге, күләме кеше организмы үсешенә, физик ныклыгына, эшләү сәләтенә, авырулар килеп чыгышына, психик халәтенә йогынты ясый. Организмның барлык әһәмиятле функцияләр эшчәнлеге туклану белән бәйле. Сыйфатлы ризык организмда яңа күзәнәкләр, яңа тән тукымасы барлыкка килүгә, энергия өстәлүгә китерә. Азык организмда ферментлар, гормоннар һәм башка матдәләр алмашы процессын көйли. Дөрес тукланмау яисә кирәгеннән артык туклану өлкән кешенең дә, баланың да, яшьләрнең дә сәламәтлегенә тискәре йогынты ясый. Бу физик һәм акыл үсешендә, әйләнә-тирә мохит тәэсиренә организмның ни дәрәҗәдә каршы торучанлыгында чагыла. Моның нәтиҗәсендә кеше тиз картаерга, гомере кыскарырга мөмкин.

Гастрит, ашказаны җәрәхәте ише киң таралган авырулардан тыш, дөрес тукланмау нәтиҗәсендә еш очрый торган авырулар – алиментар дистрофия (аксым калориясе җитмәү), авитаминоз (цинга, рахит, пернициоз анемия), симерү, диабет, үт куыгына таш утыру, атеросклероз һ.б. Күп кенә алга киткән илләрдә симерү чиренең артуы күзәтелә. Бу – шулай ук ризыкны дөрес кулланмау нәтиҗәсе. Симерү йөрәк-кан тамырлары авырулары китереп чыгара, шикәр чире, төрле органнарга ташлар утыруга этәрә. Май катламы калын булган кешеләргә операция ясау катлаулана, яралар озак төзәлә, хатын-кызларга йөклелекне кичерү, бала табу кыенрак бирелә.

Һәркем өчен дә туклану рационында махсус катнашмалы ризыкка караганда, табигый азыкны күп куллану файдалы. Һәрдаим уку белән мәшгуль булган студентлар өчен бигрәк тә. Витаминнарга бай продуктны организм җиңелрәк үзләштерә. Ә иң күп витаминнар – алдан эшкәртелмәгән табигый ризыкларда.

Организмыгызны мондый чиккә җиткереп, сәламәтлегегезгә зыян китермәсәгез, сессия-сынаулар вакытында тукланыгызга ныграк игътибар бирсәгез, күп авырулар, һичшиксез, читләп узар!

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Миннекаева, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева, Д.Р.Зиннәтова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.